**Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы**
**Керкәле авыл җирлегенең**
**Керкәле торак пункты гражданнар җыены**
**КАРАРЫ**

2024 елның 1 апреле № 5

**Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Керкәле авыл җирлегенең Керкәле торак пунктында гражданнар Җыенының «Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Керкәле авыл җирлегенең Керкәле торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салымнарын кертү турында»2023 елның 18 ноябрендәге 2 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 22 ноябрендәге 909 номерлы (29.11.2023 №1532 редакциясендә) карары белән расланган гражданнарның үзара салым акчаларын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибенең 2 пункты белән,Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Керкәле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 24.1 статьясы нигезендә, 2024 елның 1 апрелендәге «Сез 2023 елның 18 ноябрендәге 5 номерлы «Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Керкәле авыл җирлегенең Керкәле торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» карары һәм 2023 елның 18 ноябрендәге 6 номерлы «Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Керкәле авыл җирлегенең Керкәле торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында» карарына үзгәреш кертү турында 2024 елның 1 апрелендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Керкәле авыл җирлегенең Керкәле торак пунктында гражданнар җыены КАРАР БИРДЕ:

1. «Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Керкәле авыл җирлегенең Керкәлеторак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 18 ноябрендәге 5 номерлы һәм «Керкәле авыл җирлегенең Керкәле торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салымнарын кертү турында» 2023 елның 18 ноябрендәге 6 номерлы карарларына үзгәрешләр кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

1) торак пункт территориясен төзекләндерү (Керкәле торак пунктында җәйге вакытта кул белән үлән чабу (килешү буенча түләү));

2) су белән тәэмин итү һәм су чыгару системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне (Керкәле торак пунктында суүткәргеч төзү һәм ремонтлау)тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;

3) торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту (Керкәле торак пунктында Җәлил урамы, Вахитва урамы, Тукай урамы, Заря урамы, Яңа авыл урамы, Ленин урамы буенча юлларны кардан чистарту; Керкәле торак пунктында Вахитов урамы буенча вак таш җәю)

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Керкәле

авылы,Совет урамы 93нче йорт адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында, Лениногорск муниципаль районының рәсми Интернет-сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.r) кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Лениногорск муниципаль районы
«Керкәле авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы Л.И.Бигманов